# Нәсыйхәт

Җомга 12 апрель 2013 №22

**Рәхимле вә Шәфкатьле АЛЛАҺ исеме белән**
**Мамадыш мәдрәсәсенең айлык дини-иҗтимагый газетасы**

## Яңалыклар

### МӨГАЛЛИМНӘР ҖОМГА НАМАЗЛАРЫНДА

Мәдрәсә мөгаллимнәре тарафыннан авыл мәчетләрендә җомга намазлары укытыла. Әлеге чараның максаты авылларда халыкның дин белән кызыксынуларын арттыру, имамнар белән аралашу, мәдрәсәгә яңа шәкертләр җәлеп итү. Чираттагы җомга Түбән Ушма авылы мәчетендә үткәрелде.

### ШӘКЕРТЛӘР ТУПЛАНА

Мамадыш мәдрәсәсе җитәкчелеге халыкның белем дәрәҗәсен күтәрү өстендә эшли. Бу эшнең нияте иң элек укып чыккан мөселманнарның Аллаһка табынып яшәүләре, белемнәрен башкаларга да тарату, районыбызда белемле, тиешле дәрәҗәле имамнар, Ислам нигезләренә өйрәтүче укытучылар һәм башка дин белгечләрен булдыру. Шуңа күрә яңа уку елына күбрәк яшьләрне җыю күздә тотыла.

### ҖЫЕЛЫШТА БУЛАЧАКЛАР

13нче апрельдә мәдрәсә җитәкчелеге һәм мөгаллимнәре Яр Чаллыда Ак Мәчет бинасында узачак җыелышта катнашачаклар. Бирегә мәдрәсәләргә кагылышлы мәсьәләләр күтәреләчәк.

### ИГЪЛАН

“Нәсыйхәт” газетасы ислам тематикасына багышланган “Иң яхшы дини мәкалә” һәм “Иң яхшы дини шигырь” дип аталган конкурс игълан итә. Җиңүчеләрне истәлекле бүләкләр көтә. Һәр катнашучының иҗади җимешләре безнең газетабызда бастырылачак. Аларны мәдрәсәнең электрон почтасына (mamadysh-medrese@mail.ru) яки хат рәвешендә адрес: М. Җәлил ур. 8/28

# КАМИЛ СӘМИГУЛЛИН МАМАДЫШТА



**6нчы апрель көнне мәдрәсәдә күренекле ваkыйгa булды: Татарстан мөфтие вазыйфаларын үтәүче, Казанның “Тынычлык” мәчете имам-хатыйбы Камил хәзрәт Сәмигуллин килде һәм бирегә җыелган имамнар белән очрашты.“Киләчәк эшчәнлектә төп өч ноктаны билгелим. Аның иң беренчесе–мөселманнар арасында бердәмлек җитми. Ләкин мин низаг өчен бер генә дә сәбәп таба алмыйм. Динебез уртак, бердәм булыйк, безне таркаулык бер дә бизәми. Барлык дин кардәшләремне үзара дус-тату булырга чакырам”,–диде ул.**

**Имамнар аңа үзләрен кызыксындырган сорауларын бирделәр һәм төпле җаваплар ишеттеләр. Чара җылы мөхиттә үтте.**

Укучы хаты

# САБЫРЛЫК

**Сабырлык–ул кешенең теләге белән бәйле күркәм холык көче.**

Бу көч белән кеше авырлыкларны, авыртуларны, арыганлыкларны күтәрә һәм тиз ачулану, курку кебек башка кимчелек сыйфатлардан үзен саклый. Сабырлык белән кеше һәрбер нәрсәне үз урынына куеп, сәламәт акыл белән уйлап һәм үлчәп дөрес эш итә ала. Ә сабырсызлык белдергән кеше, хәтта ул изгелек эшләргә теләсә дә, киресенчә, ашыгып, уйламыйча, күпчелек вакыт хаталанып эш итә. Ислам кешеләрне мәшәкатьләргә, төрле авырлыкларга, кайгы-хәсрәтләргә сабыр һәм дә Аллаһы Тәгаләнең тәкъдиренә риза булырга өнди. Шулай ук аларга килгән яхшылык Аллаһтан, ә авырлыклар һәм кайгы-хәсрәтләр кешеләрнең үз сәбәпләреннән икәнлеген белдерә. Әгәр дә Аллаһы Тәгаләгә итагать итеп, Аның тәкъдиренә риза булып вә ризалыгын өмет итеп сабыр итсәләр, аларга зур әҗер - савап булачагы белән вәгъдә итә. Кеше тормышында сабырлык барча файдалы гамәлләрдә дә кирәк. Ризык кәсеп итү, кешеләр белән мөгамәлә кылу, гыйбадәт, шәригатебез кушканнарны үтәү, хәрам һәм мәкрүһ гамәлләрдән саклану, тормыш авырлыкларына бирешмичә алга бару сабырлыкка мохтаҗ. Моңа шулай ук Коръән аятьләре дә ишарә итә: “Ул Аллаһ, җир вә күкләр, һәм алар арасында булган нәрсәләрнең Раббысы, Аңа гыйбадәт кыл, һәм гыйбадәттә нык сабыр бул! Син беләсеңме Аңа тиңне? Юк әлбәттә ”!

Ачу тотсаң, ярсыган вакытта үзеңне кулга алып тынычлана һәм шулай ук явызлыкка яхшылык вә изгелек белән җавап бирә алмыйсың. Яхшылык белән явызлык бер тигез булмаслар, чөнки яхшылыкта файда вә савап бар, явызлыкта зарар һәм газап бар. Әгәр сиңа берәү явызлык кылса, син аңа җавап итеп яхшылык кыл, ул сиңа явызлыкны дошманлык белән кыладыр, әмма син сабыр ит һәм дә аның явызлыгына каршы һәрвакыт изгелек ит, соңра ул синдә явызлыкның юклыгын белеп, явызлык итүеннән туктар һәм тәүбә итеп синнән гафу сорар, аннары бер - берегезгә якын дус булырсыз. Ләкин бу эшне һәркем эшли алмас, көчле иманлы, чын сабыр мөэминнәр генә эшли алырлар. Явызлыкка каршы изгелек итү һәрбер кешегә бирелмәс, олуг бәхетле, күркәм холыклы кешегә генә бирелер.

Безнең мәдрәсәдә гыйлем алуыбыз да сабырлыкка мохтаҗ. Әлхәмдүлилләһ, без бу елда Аллаһы Тәгаләнең ярдәме белән, сабыр гына өч курсны тәмамлап, киләсе елга исән-сау булсак, 4нче курска киләчәкбез, иншалла. Аллаһы Тәгалә һәр барчабызны да ярдәменнән ташламасын. Сабыр илә гыйлем алуыбызны насыйп итсен.

**МӨНИРӘ НӘБИУЛЛИНА,**

**3нче курс шәкерте.**

# ДӨНЬЯ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

**ИҢ ЯХШЫ МӨСЕЛМАН ФИЛЬМНАРЫ ЯҢАДАН КҮРСӘТЕЛӘ**

“Фестиваль кайтавазы” дип аталган программа республиканың 26 шәһәрендә күрсәтеләчәк.

10-30 апрель көннәрендә Татарстанда Халыкара мөселман киносы фестивалендә катнашкан иң яхшы фильмнар күрсәтелә. Бу хакта фестивальнең рәсми сайты хәбәр итә. “Фестиваль кайтавазы” дип аталган программа республиканың 26 шәһәрендә – Казанда “Мир” кинотеатрында, Түбән Камада, Бөгелмәдә, Лениногорскида, Минзәләдә, Алабугада, Зәйдә, Сарманда, Пирәчтә һ.б. урыннарда күрсәтеләчәк.

Тамашачыларга В.Глаголеваның “Бер



сугыш”, Б.Башның “Зефир”, А.Чианчиның “Югары кат сул канат”, Р.Төхвәтулинның “Бөркетләр”, С.Р.Мир-Кәриминең “Шикәр шакмагы”, фильмнары тәкъдим ителәчәк. Программаны XVIII Халыкара мөселман киносы фестивале лауреаты булган “Әбү, Адәм улы” тулы метражлы нәфис фильмы ачачак.

**Чыганак: “Татар-информ”**

**ИНГУШЕТИЯ ИЛБАШЫ «СӨЛӘЙМАН» МӘЧЕТЕНДӘ БУЛДЫ**

3 нче апрель көнне Ингу-



шетия Илбашы Юныс бәк Евкуров Казандагы «Сөләйман» мәчетенә килде һәм Россиядә күзләре күрмәүче мөселманнар өчен бердәнбер саналган Тернәкләндерү үзәге әһелләре белән танышты. Татарстан җитәкчелеге ягыннан аны Премьер-министр Илдар Халиков һәм Татарстан Президенты аппараты җитәкчесе урынбасары – Татарстан Президенты Департаментының эчке сәясәт мәсьәләләре буенча җитәкчесе Александр Терентьев, Казанның Мәскәү һәм Киров районнары башлыгы Дамир Фәттахов озатып йөрде.

**КАЗАНДА «ИСЛАМ-ONLINE» БӨТЕНРОССИЯ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ ҮТКӘРЕЛДЕ**



4 апрельдә Казанда «Ислам-online» Бөтенроссия конференциясе үткәрелде. Әлеге чара мөселман журналистларын традицион ислам кыйммәтләрен дәгъватлауда берләштерү максатын истә тотып уздырылды.

**ИЛДАР ХӘЗРӘТ БАЯЗИТОВ РФНЕҢ ИҖТИМАГЫЙ ПАЛАТАСЫНДА ЧЫГЫШ ЯСАДЫ**

28 нче март көнне Россия



Федерациясенең Иҗтимагый палатасында “Социаль хезмәт - Россиядәге дини конфессияләр үсешенең бер өлеше” дигән темага “түгәрәк өстәл” утырышы уздырылды. Анда төрле дин әһелләре, сәясәт һәм киң җәмәгатьчелек вәкилләре катнашты. Әлеге чараның оештыручылары – Иҗтимагый палатаның милләтара мөнәсәбәтләр һәм вөҗдан иреге буенча комиссиясе белән РФ Дәүләт Думасының иҗтимагый берләшмәләр һәм дини оешмалар эшләре комитеты.

“Түгәрәк өстәл”дә Татарстаннан республика мөфтие вазыйфасын башкаручы Камил хәзрәт Сәмигуллинның урынбасары, “Сөләйман” мәчете имам-хатибы Илдар хәзрәт Баязитов чыгыш ясап, исламдагы социаль хезмәтнең мөһимлеген билгеләп узды.

**ХАҖ ЮЛЛАМАЛАРЫНЫҢ БӘЯСЕ ТӨШӘ**

“ДУМ РТ ХАҖ” компаниясе хаҗга юлламаларның бәяләре төшү турында хәбәр итә. Ул узган сезондагы кебек, 138 мең сум түгел, ә 128 мең сум булачак дип көтелә.

Аннан соң компания “Барысы да кертелгән” дип аталган яңа хезмәт күрсәтү стандарты тәкъдим итә. Ягъни хаҗилардан корбан, ихрам (хаҗ вакытында кия торган махсус кием) һәм туклану өчен өстәмә акча җыелмаячак. Үзең белән бары тик вак-төяк чыгымнарга һәм сувенирларга гына акча алырга кирәк булачак. Дубай авиакомпаниясе белән ике арадагы килешү нигезендә ул хаҗиларны Казаннан Җиддәгә кадәр алып барачак һәм алып кайтачак, Дубай шәһәрендә бер очкычтан икенчесенә күчеп утырырга кирәк булачак.



**“ДУМ РТ ХАҖ” программасында башкаса үзгәрешсез кала дип хәбәр итә компаниянең матбугат хезмәте.**

## Тапкырлар сәяхәте

**2нче апрельдә Мамадыш мәдрәсәсе тарафыннан “Тапкырлар сәяхәте” дип исемләнгән интеллектуаль уен үткәрелде.**

Уенда мәдрәсә укучылары катнашты. Чараның максаты үзара бердәмлекне, кардәшлекне арттырып, алган белемнәрне тикшереп карау иде. Тамашачылар да игътибарсыз калмадылар. Алар өчен дә дини сораулар әзерләнгән иде. Уенда җиңүне мәдрәсәнең 3нче курс талибәсе Гөлкәй Абдул кызы яулады. Суперуенда да катнашырга теләк белдерде. Һәм нәтиҗәдә абсолют җиңүче дип табылып, махсус бүләккә лаек булды. Тамашачылар да, уенчылар да ошбу уенда бик актив һәм теләп катнаштылар. Иң тапкырлары һәм сораулар-га дөрес җавап биргәннәре истәлекле бүләкләргә ия булдылар. Уен вакытында кергән намазны җәмәгать белән, саф-саф тезелеп басып уку да нур өстенә нур булды. Табын да әзерләнгән иде. Чарадан һәркем канәгать калды, әлегедәй очрашулар дәвамлы булсын дигән теләк белдерде.

## “Хатын-кыз–дөнья бизәге”

**Татарстан Диния нәзарәтендә мөслимәләр җыелды.**

Алар арасында Мамадыш мәдрәсәсе мөгаллимәсе Венера Яруллина да бар иде. “Хатын-кыз–дөнья бизәге” дигән түгәрәк өстәл утырышында гаилә, балаларны тәрбияләү, хәйрия эшләре, социаль мәсьәләләр турында сөйләштеләр. Чараны Татарстан Диния нәзарәтенең Гаилә, хатын-кызлар һәм балалар эшләре комитеты, республика мөслимәләре берлеге оештырды. Утырышның максаты–җәмгыятьтәге социаль проблемаларны чишү, сәламәт яшәү рәвешен, әхлакый тормышны пропагандалау, гаилә институтын ныгытуда мөслимә хатын-кызларның ролен арттыру иде. “Түгәрәк өстәл” утырышында Татарстанның хатын-кызлар оешмалары җитәкчеләре һәм активистлары, дини уку йортлары укытучылары, студентлар катнашты. Алар белән Диния нәзарәте башлыгы вазифаларын башкаручы Камил хәзрәт Сәмигуллин да очрашты”,–дип хәбәр итә ул.

# НАМАЗНЫҢ ГЫЙЛЬМЕ РУХ НИГЕЗЛӘРЕ

*Намаз –йөзеңнең нурыдыр,*
*Телеңнең байлыгыдыр.*
*Әгъзаларыңның куәтедер,*
*Бәденнең саулыгыдыр.*
**РӘШИДӘ ИСХАКЫЙ.**

Аллаһы Тәгалә “Бәкара” (Сыер) сүрәсенең 238 аятендә боера һәр намазны көтеп алып вакытында укырга, урта намазга игътибарлы булырга, намаз укыганда, Аллаһтан куркып, нык бирелеп укырга һәм намазда түбәнчелек белән торырга. Шушы аятьне гыйльме рух (психология) күзлегеннән ничек итеп бәяләргә? Әйе, намаз укырга әзерләнү мизгелләре безнең күңел рухы белән бәйләнгән. Бу сорау ягъни кешенең халәте белән бәйле рәвештә әлегә бик аз яктыртылган. Шулай булса да, кайбер фикерләребезне әйтеп китәргә булдык. Иң беренчеләрдән безнең төп максат булып тора (стратегия) – үзебезне ахирәт көненә әзерләү. Һиҗрәт выкытында һәр төрле кыенлыкларны җиңеп, без кыямәт көненә барырга тиеш. Менә шушы “һиҗрәт” юлында без эреле-ваклы, бетмәс-төкәнмәс тактика алымнары, ягъни ниятләр системасын (системага салынган булса бик тә хәерле) башкарабыз. Бу сорауны тирән һәм һәрьяктан аңлатырга безнең мөмкинлек юк. Гамәлләрәребез нияткә карап бәяләнә. Галәмнәрнең Раббысының сөеклесе Пәйгамбәребез (с.г.ү.с.) бер хәдисендә: “Мөэминнең нияте гамәленә караганда хәерлерәк”,–дип әйтә. Ә ният әйтелмичә башкарылган намаз гап-гади физкультурага әйләнә. Ә инде Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын алуга ниятләнгән һәр гамәл гадәткә (системага) кереп китсә, даими гыйбадәткә әйләнергә мөмкин. Ниндидер киртәләр аркасында ниятләнгән гамәл үтәлмәгән очракта, савап языла, Аллаһы Раббыбыз рәхмәте белән. Ислам дине галимнәренең, бөек имамнарның һәм тирән фикер ияләренең, Коръән кәрим һәм Нур йөзле Аллаһ Расүле (с.г.в.с.) сөннәте нигезендә нияткә багышланган тезислары бик күп. Шуларның берничәсе:

–ният – гамәлнең җаны (рухы), ә ниятсез гамәл гап-гади эш;
–тормыш шуны исбатлый, кем ниятеннән кире кайтмыйча яши, шул гына зур уңышларга ирешә ала;
–кем Җәнабел Хак Тәгаләгә ихлас күңелдән туры калу ниятендә, бары шул җәннәткә ирешә;
–тере һәм тере булмаган нигъмәтләрне, шәригать хөкемнәре нигезендә, Бөек Аллаһ ризалыгын Өмет итеп файдалансак кына зур уңышларга ирешәбез;
–ният нигезендә һәр кеше хак юлга яки яманлыкка кереп китәргә мөмкин. Бары изге ниятләр системасы яки Ислам гакыйдәсе генә безне төп максатка алып бара ала;

Нияткә дә әзерләнергә кирәк. Тиешле (фарыз) тәһарәт яки гөсел–иң беренчеләрдән санала. Хәзергә гыйльме рух фәне нигезендә шуны әйтергә була, чиста су безнең “тискәре энергияне” (гөнаһларны) үзенә сеңдерә һәм биоэнергия кырын тәртипкә сала. Безнең ниятнең нигезен тәһарәт алуга әзерләнү “төзи” башласа, тәһарәт яки гөсел бу нигезне “төзеп” бетерә. Ә инде Азан өйрәтүе буенча куелган төп максатка (стратегия) ирешү юлында системалы рәвештә 1500дән дә ким булмаган һәм һәр биш вакыт намазда бары алга, ягъни һәртөрле хаталардан арынып “югарыга” менү генә, бу дәрәҗәгә ирешергә мөмкинлек бирә. Бу яхшылап исбатланмаган, шулай да фикердә хаклык юк түгел. Ә хәзер кыскача гына шуны әйтәсе килә, һәр намазда бик җаваплы хис белән “бик яхшы билгегә” укуны тәэмин итә торган барлык мөмкинлекләрне һәм әзерлек чараларын тиешле тәртиптә үтәү, кирәксез уй-фикерләрдән һәм гамәлләрдән арыну нәтиҗәсендә генә менә бу югарыда әйтелгән дәрәҗәгә ирештерергә мөмкин. Инде, билгеле бер намазга ният әйтелгәч без


http://images.yandex.ru

күңелләрне тәмам кылып безне намазга әзерләп бетерергә тиеш. Бик яхшы гамәлләрдән санала, тәһарәт алганнан соң калган чиста суны йотымлап-йотымлап кына эчеп дога кылу. Бу да безнең метофизик киеренкелекне арттыра.

Әмин (ышанычлы) Пәйгамбәребез (с.г.в.с.) еш кына Билалга (р.г.): “Безгә бераз рәхәтлек индер!”–дип эндәшә торган була. Билал (р.г.) Азанны бик матур итеп әйтә белгән. Һәр кешенең бер яки берничә “зәгыйфь” (сыйфаты) ягы була, нәрсәгә булса да шәһвәте ягъни көчле омтылышы, теләге, мәхәббәте, сәләте яки таланты була. Ә безнең Аллаһ илчесендә (с.г.в.с.) исә намазга карата көчле теләк мәгънәсендәге шәһвәт була. Ул бер намаздан соң түземсезлек белән икенчесен көтеп алган. Ә ничек бу сыйфатка ирешергә соң? Гыйльме рух фәне шушы намаз “эчендә” генә яшәргә тиеш. Яки без менә шушы намаз белән гипнозланган булырга тиеш. Намазыбыз җәмәгать белән мәчеттә башкарыласы булса, мәчет хөрмәтенә укыласы нәфилә намазы, безне фарыз намазыбызга “әзерли”: “Бербәнбер Бөек Хак Тәгалә Синең генә ризалыгыңны алыр өчен һәм Синең генә кушканнарыңны үтәп яшәргә телим. Бөтен барлыгым (тән һәм җан) ошбу фарыз намазымны үтәргә юнәлә”. Инде мөәззин камәт төшергәч безнең җан үзенең тәне белән тәмам намазга “эрергә” тиеш.

**(Дәвамы киләсе санда.)**

.................................

**КАМИЛ ХИСМӘТОВ,**
мәдрәсәнең 1нче курс шәкерте, гер спорты буенча Европа һәм дөнья чемпионы.

## Белдерүләр

### Мамадыш мәдрәсәсенә рәхим итегез!

Мамадыш мәдрәсәсе 2013нче уку елына шәкертләр туплавын дәвам итә. Белгечләр әзерләү көндезге һәм кичке уку рәвешендә алып барыла. Көндезге бүлеккә ир-егетләр кабул ителә (шәһәребездән һәм тирә-юнь авыллардан). Шәкертләр мәдрәсә тулай торагында яшәү урыны һәм көненә 3 тапкыр ашау-эчү белән тәэмин ителәләр. Уку вакыты–дүрт ел. Урта белем алу икенче санлы лицей нигезендә алып барыла. Мәдрәсәне тәмамлаганнан соң шәкертләргә квалификация комиссиясе карары нигезендә тиешле белгечлек алу турында диплом бирелә. Намаз укырга өйрәнергә һәм дин белемен үзләштерергә теләүчеләр өчен мәдрәсәдә кичке уку бүлеге һәм читтән торып уку бүлеге эшли. Бу бүлекләргә хатын-кызлар һәм ир-егетләр кабул ителә. Яшь чиге куелмаган.

**Безнең адрес: Татарстан Республикасы, Мамадыш шәһәре, М. Җәлил урамы 8/28, Телефоннар: 3-19-17, 89172802391**

*Мәдрәсә базасында атнаның һәр ялында балалар өчен әхлак дәресләре алып барыла.
*Мәдрәсә бинасында ислам атрибутикасы кибете эшли. (Коръән китаплары, шамаилләр, тмин майлары, дисбеләр, дини китаплар, түбәтәйләр һ.б.)
*Балага исем кушу, никах уку һәм башка дини мөрәсимнәрне үткәрү. Мамадыш мәдрәсәсе, М. Җәлил ур 8/28), тел: 89172802391
*Намаз, Коръән укырга, дин гыйлемен өйрәнергә теләгән һәр кешене мәдрәсәдә оештырылган кичке уку курсларына чакырабыз.
*Мамадыш мәдрәсәсе ял курсларына укучылар җыя. Укулар һәр атнада 9:00-13:00 сәгатьләрдә дәвам итәчәк. Яшь категориясе чикләнмәгән.
*Мамадыш мәдрәсәсе читтән торып уку бүлегенә укучылар җыя. Укулар елга ике мәртәбә (1-10 гыйнвар һәм 20-30 апрель) оештырыла. 10 көн дәверендә мәдрәсәдә белем алачаклар. Торак һәм ашау-эчү каралган.

# Әби хаты

**(Дәвамы. Башы 21нче санда)**

Резедә Шәфкатовна дәфтәренә тиз генә нәрсәдер язды да, урындыктан торып, ишеккә юнәлде.

–Бүгенгә сау булып тор, Сиринә. Үзеңне сакла, җомга көнне дәвам итәрбез. Килештекме?

–Ярый. Сау булыгыз. Рәхмәт сезгә.

Көн арты көн үтте. Сиринә хыял дөньясында яшәвен дәвам итте. Хыялында–авыл, су буе һәм әбисе булса, чынлыкта аның палатасында шәфкать туташлары һәм доктордан башка беркем күренмәде.

Беркөнне хастаханәгә ромашкалар тотып бер егет керде. Кешеләр кабул итүче шәфкать туташы сораулар яудыра башлаганчы, чәчәк тоткан егет сорауны үзе бирде.

–Исәнмесез, уналтынчы палатаны күрсәтә алмассызмы?

–Димәк, сез Сиринә Идрисовага?

–Әйе, нәкъ шулай.

–Хәзер ул йоклый, әгәр дә көтәсегез килсә, әнә тегендәге урындыкка рәхим итегез,– диде шәфкать туташы.

–Рәхмәт.

Сиринә, йоклаган кыяфәт ясап бер сәгать чамасы ятканнан соң, коридорга чыгарга уйлады. Бүлмәсендәге ялгызлыктан ул тәмам арыган иде инде. Ишекне ачып, берничә адым атлап киткәннән соң, ул шәфкать туташының тавышын ишетте.

–Идрисова, сез кая җыендыгыз?

–Монда гына.

–Хәзер үк палатага. Сезгә йокларга кирәк.

–Минем йоклыйсым килми.

–Миңа каршы килмәгез. Әйдәгез мин сезне палатагызга озатам.

–Юк, кирәкми, мин юлны беләм.

Сиринә сөйләшүнең файдасыз булачагын аңлагач, палата ягына борылды. Ләкин таныш тавыш аны туктарга мәҗбүр итте.

–Сиринә...

–Йә Раббым, Ирек, син мине таптың?!

–Әйе, кадерлем!–диде Ирек, Сиринәне кочаклап.– Ничек хәлләрең?

–Хәзер әйбәтләнде. Ирек, алып кайт мине авылга. Миңа әбине күрергә кирәк.

–Көтеп тор, мин доктор янына кереп чыгам.

–Мин палатада булырмын.

Сиринә, киемнәрен җыйганда, палатага Шәүкәт Кадырович белән Ирек керделәр. Беренче булып сүзне доктор башлады:

–Сиринә, сезнең күңел



халәтегез минем өчен һаман да кара урман булса да, мин шуны әйтә алам, сезгә тормыш авырлыклары алдында көчле булырга кирәк. Сез артык нечкә күңелле һәм шул сыйфатыгыз сезне эчтән җимереп килә. Мин сезне тагын берничә көнгә хастаханәдә калдырыр идем, тик нәтиҗә уңай булмас кебек. Сезгә иң яхшы дәва–күңел тынычлыгы. Ә сезнең бурычыгыз, Ирек Вәлиевич–сөйгәнегез турында кайгырту.

–Әлбәттә, –диде Ирек, аңа кулын сузып.

–Рәхмәт сезгә, доктор!–дип сүзгә кушылды Сиринә.

–Бик зур рәхмәт. Ниһаять, авылга, Ирек. Ниһаять...

Сиринәнең балачагы узган урам бераз үзгәргән. Йортларларга яңа төс керткәннәр, урам ахырына яңа кибет салганнар, эскәмиядә сөйләшеп утыручы әбиләр генә шул ук. Алар Сиринәне бер күрүдә танып алдылар.

–Карале, син Мәликә кызы түгелме соң?

–Шуныкы, Галия апа, шуныкы. Ә әби кайда соң? Капкасы эчтән дә, тыштан да бикле. Хәтта тәрәзәләргә дә такта кадаклап куйганнар.

Саймә апа эшнең асылына төшенде.

–Кунак кызын болай бастырып тору ярамас, әйдә, кызым, минем өйгә. Хәзер барысын аңлатам,–диде ул. Сиринәне үз өенә алып кереп китте. Ирек тә, сумкаларны алып, алар артыннан иярде. Саймә апа чәй әзерләгән арада, Сиринә кучтәнәчләрне өстәлгә куя торды. Чәй кайнап җиткәч тә, Саймә апа сүз башларга ашыкмады.

–Әйдәгез, Саймә апа, сөйләгез инде,– диде Сиринә, түзмичә.

–Соңгы араларда әбиең бик авырайды. Кан басымы белән интекте бит. Урамда сирәк күренә башлагач, мин аңа бер көнне үзем кердем. Ул хат яза иде. Аптырадым, ник дисәң, аның өй телефоны бар бит. Кемгә хат язасың дип сораган идем, ул, берни әйтмичә, язуын дәвам итте. Мин ишектән чыгарга җыенганда, янына утырырга кушты. Хатны озак язды, язып бетергәннән хатны конвертка салды, аннан елап алды. “Ни булды соң сиңа, Мәликә?”–дип сорагач, ул зират ягына карады да: “Миңа вакыт җитеп килә!”– диде. Аннары чәй куеп җибәрде. Без тәмләп чәй эчтек. Башка сораулар биреп газапламадым. Чыгып киткәндә, ул миңа менә шушы конвертны тапшырды,”–диде Саймә апа.

–Кайчан үлде әби?

–Теге атна башында, үнечендә.

–Нишләп миңа беркем дә хәбәр итмәде?

–Синең хәлең болай да авыр иде, син ул кайгыны кичерә алмас идең.

–Ләкин бер атна эчендә хәлем әллә ни үзгәрмәде.

–Шулай да хәзер сиңа карап мин икенче кешене күрәм. Өстәвенә син ялгызың түгел, янында Ирек бар.

–Әбине эти һәм әни янына күмделәрме?

–Әйе. Кызым, син хатны укы, әбиең тикмәгә язмагандыр аны. Мин чыгып торам.

Сиринә конвертны ачкач та, хатны укырга икеләнеп торды. Бераздан соң үзен кулга алып, күзләрен хатка төшерде.

“Бисмилла дип башлыйм әле хатымны, кызым. Бигрәк авыр икән соңгы хатны язу. Кызым, сине бик сагындым. Һәр иртә юлларга чыгып сине көткән чаклар да булды. Апаң шалтыратып, Сиринә эшләре буенча икенче шәһәргә китте дигәч, мин тәмам үз эчемә бикләндем, ялгызлык биләде өемне. Әлхәмдүлилләһ, Аллаһы Тәгалә мине ярдәменнән ташламады, күрше-күләннәргә якынайттым, алар белән аралашу бердәнбер сөенечемә әверелде. Менә шулай итеп, мин ямьсез уйларымнан котылгандай хис иттем үземне. Бу ел минем өчен авыр башланды, кызым. Башта баш авыртуы тынгы бирмәде, аннары кан басымы уйный башлады. Шулвакытларда бердәнбер якты уем син идең, балам. Авырганда синең хакта уйладым, Аллаһыдан сиңа бәхет сорадым. Август аенда хәлем авырайды. Намазны да утырып укый башладым. Күзләремә дә әллә нәрсә булды. Китапны ачуга, хәрефләр томан эчендә күк. Ярый, зарларым күпкә китте ахры, бу сүзләр сине бер дә сөендермәсләр, кызым, хәзер сиңа язасы төп мәсьәләгә күчәм.

**(Ахыры киләсе санда.)**

...................................

ФАЯГӨЛ ТАЛИПОВА.

Көек-Ерыкса авылы.

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең Бөек исемнәре булганга күрә, аны саклап тотуыгыз сорала**

**Баш мөхәррир: Хәбибуллин А.М. Мөхәррир урынбасары: Хәбибуллина Э.Р.**
**Дизайн һәм верстка: Мингалиева Ф.Н. Җаваплы сәркатип: Спиридонова А.С.**
**Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы,8/28. mamadysh-medrese@mail.ru. Газета “Татмедиа” ААҖнең Мамадыш муниципаль районы”Нократ” мәгълүмат-матбугат филиалында басылды. Тираж татар телендә 250 данә.**